КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО СОЦИАЛЬНО-
ЭКОНОМИЧЕСКОМУ
МОНИТОРИНГУ
ул. Г.Камала, д. 24 а, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ
МОНИТОРИНГ
КОМИТЕТЫ
Г.Камал ур., 24а йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон/факс (843) 292- 94- 82. E-mail: ks.em@tatar.ru, сайт: http://monitoring.tatarstan.ru

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**26.06.2019** Казан ш. **N 16-ос**

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый комитеты каршында журналистларны аккредитацияләү турындагы кагыйдәләрне раслау турында

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге № 2124-1 Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый комитеты каршында журналистларны аккредитацияләү турында кушымта итеп бирелүче кагыйдәләрне расларга.

2. Юридик сектор әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә тиеш.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны рәис урынбасары О.Ю.Семеновага йөкләргә.

Рәис В.П.Кандилов

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый комитетының 26.06.2019 № 16-ос боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый комитеты каршында журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге № 2124-1 Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый комитеты каршында журналистларны аккредитацияләү (алга таба – аккредитацияләү, Комитет) процедурасын регламентлый.

Аккредитацияләү сроксыз гамәлгә ашырыла. Массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе теләге буенча аккредитацияләү конкрет редакция биремен үтәү өчен кирәк булган срокка гамәлгә ашырылырга мөмкин, йә аккредитацияләнгән журналист вакытлыча булмаганда аны алмаштыру очрагында (вакытлыча аккредитацияләү).

## II. Аккредитацияләүгә хокук

2.1. Аккредитацияләү хокукына милек рәвешенә һәм гамәлгә куючылар составына карамастан, массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе ия була, шул исәптән чит илләрнең массакүләм мәгълүмат чаралары да. Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасы журналистын аккредитацияләү өчен Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аны аккредитацияләүне раслау кирәк.

## III. Аккредитацияләү тәртибе

3.1. Аккредитацияләүгә гарызнамә массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясе җитәкчесе имзасы белән Комитетның шушы гарызнамәне алуы фактын, датасын һәм вакытын раслый торган теләсә нинди башка алым белән Комитетка тапшырыла.

3.2. Гарызнамәдә журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), аның вазыйфасы, эш һәм мобиль телефоннары номерлары, электрон почтасы адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү датасы һәм таныклыгы номеры күрсәтелә.

Вакытлыча аккредитацияләүгә гарызнамәдә шулай ук редакция биреме һәм аны үтәү чоры, аккредитацияләнгән журналист вакытлыча булмаганда аны алмаштыру очрагында – аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда) һәм алмаштыручы журналистны аккредитацияләү срогы күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чарасы журналистын аккредитацияләү өчен Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аны аккредитацияләүне раслаучы документлар күчермәләре өстәмә рәвештә кушып бирелә.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килмәгән гарызнамәләр каралмый.

3.4. Аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турындагы карар Комитет рәисе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – Рәис) тарафыннан гарызнамә кергән көннән ике эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Мондый карар Рәиснең тиешле боерыгы бастырып чыгарылган көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча гарызнамә җибәргән редакциянең аны алуы фактын, датасын һәм вакытын раслый торган теләсә нинди алым белән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсуслаштырылган характерда булган (реклама тарату, эротик басма) очракта, аккредитацияләүдән баш тартыла.

3.6. Аккредитацияләү турындагы гарызнамәне карау, аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турында Комитет Рәисе боерыгы проектын әзерләү, шулай ук массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә кабул ителгән карар турында хәбәр итү Комитетның матбугат хезмәтләре белән эшләүче һәм җәмәгать белән бәйләнешләр бүлеге тарафыннан әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокта гамәлгә ашырыла.

## IV Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәге хокукларга ия:

чарада булырга;

чара турында Комитетта булган рәсми документлар (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмат-белешмә, статистик, аналитик һәм бүтән материаллар) күчермәләрен алырга;

бастырып чыгару өчен билгеләнгән мәгълүмат-белешмә материаллар белән танышырга;

Россия Федерациясе законары белән каралган бүтән хокукларга.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистларның бурычлары:

чара регламентын үтәргә һәм, әгәр чара массакүләм мәгълүмат чарасы өчен махсус оештырылган булмаса, аның барышына катышмаска;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска;

Комитет биргән пресс-релизларны, мәгълүмат-белешмә, статистик, аналитик һәм бүтән материалларны бастырып чыгарган әсәрләрендә (эфирда эшләгәндә) кулланганда, мәгълүмат чыганагын күрсәтергә;

үз һөнәри эшчәнлеген башкарганда Комитет эшчәнлеге турында дөреслеккә туры килмәгән белешмәләрне таратмаска.

---